СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №34 (7207) | 23 март, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы КАРАРЫ

Товарларга һәм хезмәт күрсәтүгә бәяләрнең күтәрелүе алдыннан компенсацияне уңышлы үткәрү максатында түбәндәге составта район комиссиясен төзергә:

Г. Ш. НУРГАЛИЕВ—комиссия рәисе, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары, район план комиссиясе рәисе.

Комиссия членнары:

Р. Г. БИЛАЛОВ—район финанс бүлеге мөдире.

В. Ф. ГАЙСИН—Саклык банкының район бүлеге управляющие.

Р. Э. ГАЙФЕТДИНОВ—район элемтә узелы начальнигы.

Л. Н. ДИЛЬМӨХӘММӘТОВА—район Советы башкарма комитетының социаль тәэминат бүлеге мөдире.

В. В. ИВАНОВ—район эчке эшләр бүлеге начальнигы.

А. М. ФАДЕЕВ—Агропромбанкның район бүлеге управляющие.

x x x

Комиссия халык депутатларының район Советы башкарма комитетының 15 бүлмәсенә (икенче катта) урнашкан. Язма үтенеч һәм гаризалар белән шунда мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Телдән мөрәҗәгать итү өчен телефон номеры: 2—15—81.

Әйдәп баручылар

Һәрбер эшнең үз осталары, әйдәп баручылары булган кебек безнең «Игенче» колхозының сөтчелек фермасының да үз маяклары бар. Фермабызда 18 савучы алмаш белән эшләп киләләр. Февраль аенда үзләренә бирелгән планны күпкә арттырып үтәүчеләребез булды. Зәйтүнә Гыйльфанова белән Камилә Әһлиуллина үзләренә беркетелгән һәр сыердан 189 килограмм урынына 204 һәм 195 килограмм сөт савып айлык планны 109 һәм 103 процентка үтәделәр. Таналар группасында эшләүче Гөлзада Садретдинова һәр берсеннән уртача 325 килограмм сөт савып айлык планын 191 процентка җиткерде. Рәзинә Сәлахова да үз группасындагы таналардан уртача 317 шәр килограмм сөт савып алды, бу 186 процент тәшкил итә.

Билгеле, моның өчен алар бөтен тырышлыкларын бирделәр. Март ае йомгаклары да куанычлы булыр дип көтелә.

В. КАНӘФИНА,
экономист.

Хезмәтен хөрмәтләп

Нефть производствосында озак еллар, нәтиҗәле эшләгәне, җәмәгать эшләрендә актив катнашканы өчен Норлат геофизик эшләре идарәсе работнигы ВИКТОР МИХАЙЛОВИЧ ХАЛИПА КПСС райкомы һәм халык депутатларының район Советы башкарма комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Рөстәм үзенең гомерен шофер хезмәтенә багышлаган Мотыйгулла абзый улы. Үз вакытында өлкән Гарифуллин Ульянов исемендәге колхозның нинди генә йөген йөртмәде, кайларда гына булырга туры килмәде аңа. Гомерен машинага багышлап, шуннан пенсиягә китте ул. Әтисе янында утырып йөргәндә үк Рөстәм техниканы ярата иде инде, бик бәләкәйдән машинаны идарә итәргә дә өйрәнде.

Инде менә автопредприятие хуҗалыгына килгәнгә дә аңа 19 ел тулып үткән. Бу чор эчендә уңган шофер үз машинасы белән илебезнең төрле төбәкләрендә, ерак рейсларда булды. Советлар Союзын аркылыга-буйга иңләде. Аның машинасы һәрвакыт төзек, үзе беркайчан күңелен төшерми торган кеше. Ел саен алган йөкләмәсен үтәп килә. 1990 елдан да 538 мең 908 тонна-километр юл үткән, хуҗалыкка китергән доходы да акчага күчергәндә 103,4 процент тәшкил итә.

—Быел да Рөстәм эшен уңышлы дәвам итә, смена заданиесен һәрвакыт үтәп килә,—ди эш һәм хезмәт хакы бүлеге экономисты А. Белянина.—Чисталыгы, пөхтәлеге, техниканы сак тотуы белән дә күпләргә үрнәк.

Рөстәм ярдәмчел, иптәшләренә һәрвакыт булышуы белән дә шоферлар арасында ихтирам казанды. Аннары җилкәсендә егерме елга якын тәҗрибәсе булган шоферга яшьләр дә бик теләп мөрәҗәгать итәләр. Үзе белгәнне өйрәтә ул, иренми.

«Юлга чыксаң, юлдашың яхшы булсын», диләр икән, бу нәкъ аңа әйткән кебек.

Хәерле, тыныч юллар сиңа, Рөстәм!

Рәсемдә: автопредприятие шоферы Р. Гарифуллин.

Икенче бригада эшен төгәлләде

Язның беренче хәбәрчеләре булып кара каргалар да килде. Түбәләрдән тамчылар тама, көн үзәгендә урамнарда сулар җыела башлады, көннән-көн рәхимлерәк карап кояш язны ашыктыра.

Менә шушындый шартларда Берлек авылын үз эченә алган икенче бригада механизаторлары язгы чәчүгә хәзерлекне тәмамладылар диярлек. Аталы-уллы Җәмил һәм Сәлим Сөләймановлар, Фәрит Галимов, Касыйм Ахунҗановлар техниканы соңгы кат күздән кичерәләр. Кызу чәчү өстендә тоткарлык булмасын дип тырышалар. Биредә авыр тырмалар, ике комплект культиватор, ике комплект чәчкеч һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарын бүген эшкә кулланып була.

Җайланмалар үзләре генә кырга чыкмас, шуңа күрә тракторчыларыбыз да үз машиналарын җентекләп тикшереп чыктылар. Бригадада биш—ДТ-75, өч—Т-70, ике—Т-150, К-700 тракторлары бар. Үткән ел үзләрен кыр эшләрендә булганлыкларын күрсәткән механизаторларыбыз быел да әйбәт эш нәтиҗәләре күрсәтерләр. Ринат Вафин К-700 маркалы трактор белән бик яхшы эшләгәч аны комплектлаштыру буенча ул колхозда алдынгы урыннарның берсен яулады. Фәрит Галимов, Ислам Бәхтияров, Марат Ахунҗановларның да корыч атлары бүген басуга алып чыгарлык.

Г. КУЛЬМЕТЬЕВА,
«Знамя Октября» колхозы экономисты.

КПСС райкомы бюросы утырышында

21 мартта КПСС райкомы бюросы утырышы булып үтте.

Көн тәртибендәге төп мәсьәлә «1990 елда һәм 1991 елның ике аенда район партия оешмаларының торышы һәм КПСС сафларыннан чыгуның сәбәпләре» турында иде. Бу мәсьәлә буенча информацияне КПСС райкомы партоештыручысы В. И. Трембовицкий ясады. Фикер алышуларда Иске Чаллы участок больницасы баш врачы КПСС рескомының ревизия комиссиясе члены А. Л. Клементьев, НГДУ, НУРБ, шикәр заводы, АТП, «Октябрьскремтех п р е д», «Правда» колхозы, тимер юл станциясе, СПТУ, «Знамя Октября» колхозы партия оешмасы секретарьлары А. П. Шамкин, Н. А. Альферов, П. П. Хармушков, В. В. Мещеряков, М. В. Белянин, И. В. Григорьев, В. М. Рассадин, В. М. Исхаков, П. П. Иванов һәм «Фармация» район берләшмәсе управляющие Н. И. Лесняков иптәшләр катнаштылар.

Бюро тикшерелгән мәсьәлә буенча карар кабул итте.

Бюро утырышында район партия оешмасының эшчәнлегенә бәйле башка кайбер мәсьәләләр дә каралды.

СЕМИНАР ҮТТЕ

21 мартта КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов җитәкчелегендә башлангыч партия оешмалары секретарьлары семинары булып үтте.

Анда КПСС райкомының оештыру-партия һәм башлангыч партоешмалар эшчәнлеген яңарту комиссиясе рәисе урынбасары Ф. Ш. Галимов 17 мартта үткән СССР референдумы йомгаклары белән таныштырды. КПСС Уставы таләпләрен үтәү буенча партоешмаларның бурычларына тукталды. КПСС райкомының партия учеты секторы мөдире В. Г. Хоменко партия членнарын учетка алу, взнос түләү һәм отчет бирү тәртипләре белән таныштырды. КПСС райкомы секретаре А. А. Коростелев язгы кыр эшләре чорында партоешмаларның бурычларына тукталды.

Семинар эшенә Х. Х. Морадыймов йомгак ясады.

Яз җитте

Икенче бригада колхозыбызда эре бригадаларның берсе. Биредә техника да, механизатор кадрлар да җитеш. Техниканың язгы хәзерлеген тикшерү, аның комплектлаштыру буенча механизаторларыбыз әйбәт эшләде. Агрегатларны хәзерләүдә Әнәс Җамалетдинов, Марс Билалов, Рәмис Сафин, Әнәс Гыйләҗевлар зур тырышлык күрсәттеләр. Ике агрегат уҗым тукландыру өчен, ике агрегат чәчү өчен хәзерләнде. Җиде культиватор ремонтлап куелды, дым каплату өчен дә җиде агрегат хәзерләнде.

Билгеле, ремонт эшләре вакытында тимерчеләрнең хезмәте һәрвакыт кирәк була. Бу яктан Әнәс Вафин, Шәяхмәт Галләмов югары квалификацияле эшчеләр икәнен күрсәттеләр. Алар биредә озак еллар эшлиләр инде, шуңа күрә нинди генә детальне төзәтергә, яки яңадан ясарга кирәк булса, алар аны бик яхшы үтәп чыгалар.

Э. ГАФИЯТУЛЛИН,
Ульянов исемендәге колхоз.

«Солдат хатлары» кичәсе

Авылыбызның 21 егете армия сафларында хезмәт итә. Совет Армиясе һәм Хәрби-Диңгез Флоты көне алдыннан алар хөрмәтенә авыл культура йортында «Солдат хатлары» кичәсе үткәрелде.

Кичәне укытучылар Нагыйф Шәһитов һәм Люция Шәйнурова алып бардылар. Алар хәрби хезмәттәге якташларыбызның хатлары белән таныштырдылар. Хатлар илебезнең төрле почмакларыннан: Ерак Көнчыгышта хезмәт итүче Фәнис Шәкүровтан, Свердловскидагы Равил Сәхиповтан, Караганда өлкәсендәге Азат Гафиятуллиннан, Казахстандагы Фаикъ Могыйновтан, Германиядә хезмәт срогын узучы Җәгъфәр Хәмәтвәлиевтан һәм башкалардан килгән иде. Егетләр үзләренең намуслы хезмәт итүләре, туган авылларын сагынулары, хезмәт срогын тәмамлагач кычатканлыга кайтачаклары турында язалар.

Программаның икенче бүлегендә солдатлар соравы буенча авыл үзешчәннәре җырлар башкардылар. Ринат Могыйнов, Фәнисә Ибраһимова, Сания Минһаҗева, Нияз Зәйнуллин башкарган җырлар солдат әти-әниләре күңеленә аеруча хуш килде. 8 нче класс укучысы Ринат Исхаковның җырларын да тамашачылар җылы кабул итте. Илнур Хөмәтвәлиев һәм Гөлнара Сабирова парлап биюләре белән тамашачылар күңелен яуладылар.

Кичәдән халык зур канәгатьлек хисе белән таралды.

З. ИСМӘГЫЙЛЕВА.
«Татарстан» колхозы.

Җитәкче сүз ала

Хыял әйди, өмет яшәтә

Норлат сөт-май заводы 1950 еллар башында төзелгән булган. Аның куәте тәүлегенә 25 тонна продукция эшкәртергә исәпләнгән. Шуңа өстәп, районның Төрнәс, Киекле, Биләр Озеро һәм башка авылларында сөт кабул итү пунктлары булган. Хәзер алар юк инде. Ә завод үзе җәйләрен тәүлегенә 130—150 тоннага кадәр сөт эшкәртергә мәҗбүр. Күз алдына китерәсездер: биналар гаҗәеп кысан, җиһазлар иске. Шуңа да карамастан, халыкка тәүлегенә 10 тонналап сөт, 2 тонна каймак, 2 тонна катык, 400—500 килограмм эремчек озатабыз. Моннан тыш Төрнәстә һәм Мамыкта 1000 гә якын пенсионер яши. Атнага 5 көн аларга катык һәм эремчек илтәбез. Әмма сөт ризыкларына булган ихтыяҗ тулысынча канәгатьләндерелә дип әйтеп булмый. Эштә төп кыенлык—заводның искелеге. Заводка реконструкция ясарга кирәк. Ә эшкәртү процессын бер генә көнгә дә туктатып торып булмый. Шуңа күрә продукция эшкәртү дә һәм ремонт та бер үк вакытта алып барыла.

Әлбәттә бу кыенлыкларны ахыргача хәл итүнең иң туры юлы бер генә —яңа завод төзү. Әмма бу әле һавадагы торна гына шул. Хәзергә яңа завод төзелеше өчен кирәкле техник-экономик хисаплау эшләре алып барыла. Төзелешне башлау 1993 елга ниятләнә. Ә гамәлгә ашуы ничек булыр —анысын вакыт күрсәтер.

Ә бүгенге көндә технологик җиһазлар һәм запас частьләр белән тәэмин итүнең кыенлашуы, тара җитмәү җанга тия.

Мөмкинлекләр шактый чикләнгән булса да узган ел ахырына без аренда ысулы белән эшләүгә күчтек. Элек барлык табышның 75—80 проценты үзебездән китә иде. Яңа ысулга күчкәч, күбрәк өлешне предприятие карамагына калдырып булмасмы дип өметләнәбез. Чөнки ремонт эшләренә дә аз чыгым тотылмый. Моннан тыш, ассортиментны киңәйтү буенча да даими эш бара. Менә әле күптән түгел генә яңа төр продукция—«Адыгейский» сыры җитештерә торган участок сафка басты. Боларның һәммәсе дә билгеле бер күләмдә өстәмә чыгым таләп итә.

Продукциянең төрлелеге ягыннан бездә тагын казеин эшләнә. (Ул азык промышленносте өчен чимал булып хезмәт итә) Узган елда без 225 тонна казеин җитештердек. Аның бер өлеше бездән чит илгә озатыла. Безнең комбинат республиканың казеин бирүче эре предприятиеләреннән берсе булып санала. Безгә хәтта Самара шәһәреннән һәм Самара өлкәсенең Шенталы, Кошка, Сергеевск районнарыннан вәкилләр килеп казеин ясау серләрен өйрәнделәр.

1990 ел безнең завод өчен чимал белән тәэмин ителеш ягыннан уңышлы ел булды. Планны үтәдек. Бер кешегә уртача хезмәт хакы да 1989 елдагыдан бераз артты. Әмма 1991 ел башыннан, кышлатуның авыр чоры буларак, сөт кимеде, шуңа күрә комбинат та үзенең җитештерү күләме белән мактана алмый. Беренче квартал планы өзелү алдында тора. Ел дәвамында чимал белән тәэмин ителеш яхшыргач, хәлне төзәтеп булыр дип өметләнәбез. Әлбәттә, коллективның тырышлыгына ышанып кына шулай дияргә була. Коллектив әйбәт бездә. Үзәге нык, тәҗрибәле белгечләр эшли. Май ясау остасы Минзатия Мирзакай кызы Зибаева, сөт тутыру линиясе операторы Миннегөл Әхмәт кызы Дилмөхәммәтова, казеин ясаучы Римма Романовна Шәйдуллина, аппаратчы Клавдия Кузьминична Ивановалар — менә шундый ышанычлы кадрлар.

Комбинатта эшчеләрнең тормыш-көнкүрешенә караган күп кенә мәсьәләләр үз җае белән хәл ителә бара. Әйтик, бүгенге көндә утызлап гаилә фатир хәлен яхшыртуны көтә. Май бәйрәме тирәләренә 22 фатирлы яңа торак йорт өлгерер дип өметләнәбез. Бу юлы бәхетлеләр исемлегенә эләгә алмаучылар турында шулай ук кичектергесез кайгырту безнең өстә кала. Үз бакчасын булдырырга, дача участогы алырга теләүчеләргә быел язда бу мөмкинлек туачак. «Большевик» колхозы территориясеннән җир мәйданы сорадык. Участокларның чагыштырмача якынлыгы да кешеләрне кызыктырыр, мөгаен. Производствоның үзенчәлекле булуы сәбәпле, эшчеләргә (ә аларның күпчелеге хатын-кызлар, ләбаса) сменага төнге сәгатьләрдә йөрергә туры килә. Шуңа күрә быел эшчеләрне йөртү өчен махсус вахта автобусы булдырдык. Ул билгеләнгән маршрут буенча көнгә өч тапкыр рейска чыга.

Кыскасы, иске шартларда яңача эшләргә, нәрсәгәдер ирешергә тырышып көн итәбез. Әлбәттә, моңа безне коллективның хыялы һәм төп максаты булган яңа завод образы әйдәп тора.

З. БИЛЬДАНОВ,
Норлат сөт-май заводы директоры.

«Комбайн» колхозында Сания Мөнировна Вәлиева дистә елдан артык хезмәт куя. Ул һәр елны җәйге чорда татлы тамыр үстерә һәм берүзе 7 гектар мәйданда чөгендер сирәкли. Бүгенге көндә Сания Мөнировна хуҗалыкның товарлыклы-сөтчелек фермасында алмаш савымчы, ә ире Фәнил исә терлекче булып эшлиләр, ике бала тәрбияләп үстерәләр.

Рәсемдә: II нче бригада чөгендерчесе Сания Мөнировна Вәлиева.

Сәхнәдә—яшь талантлар

Сәхнәдә урта мәктәп укучылары. Кече һәм өлкән класс укучылары тарафыннан зур концерт оештырылган. Соңгы елларда мәктәп укучыларыннан торган концертлар оештыру нечектер бераз сүлпәнәебрәк киткән иде, күкне каплап торган болытлар таралып, күк йөзенә сибелгән якты йолдызлар сыман берсеннән-берсе остарак башкару сәләтенә ия булган яшь талантлар бүген сәхнәдә. Авыл халкы бирелеп, йотлыгып, алкышларны мул итеп концерт карый, җаннарына рухи ләззәт алып ял итә. Ә сәхнәдә берсеннән берсе матур, курчак кебек киенгән, күбәләктәй тасмалары белән очарга талпынгандай кече класс укучылары бөтерелә. Сабыйларча ягымлы, саф тавышлары белән матур матур җырлар башкаралар. Кече класс укучылары Лилия Мусина, Гөлүсә Йосыпова, Гөлгенә Галәветдинова һәм башкалар самими саф тавышлары белән тамашачыларны бөтенләй әсир иттеләр. Ә яшь биюче Ләйсән Закирова һинд биюен, мари халык һәм татар кызлары биюләрен башкарып, тамашачыларда үзенә зур соклану хисе уятты.

Залда халыкның «биюче булып тугандыр бу, буыннары юктыр моның» дип шаккатып сөйләүләре ишетелеп торды. Өлкән класс укучылары сәхнәне тәмам моң чишмәсе иттеләр. Айдар Мусин, Альберт Галәветдинов, Зөлфия Мөхәммәтова, Миләүшә Төхфәтуллина берсеннән-берсе уздырып матур җырлар башкардылар. Ә үзенең моңы, үзенчәлекле аһәңе, йөрәкләргә үтеп кереп җаннарыңны айкарлык моңлы-сагышлы тавышлы Рамил Хаҗиморатов сәхнәгә чыккач зал бер мәл алкышларга күмелеп торды. Рамилнең сәхнәдә беренче генә чыгышы түгел. Авыл халкы аның (кечкенәдән үк) җырларын һәрвакыт яратып, көтеп ала. Рамил җырларын үзе уйнап үзе җырлый. Бу сәләт аңа яшьли үлеп киткән җырга-моңга оста әтисеннән күчкәндер, мөгаен. Әтисенең баянда уйнавыннан «үлгәннәрең терелеп биерлек» диеп сөйли торган иде авыл халкы. Ә бүген Рамил өлкәннәрне елатып, яшьләрне дәртләндереп, үзәкләрне өзәрлек итеп җыр суза. Мәктәпнең драма түгәрәге җитәкчесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәфисә Таһировна Төхфәтуллина оештырган «Сабан туй» күренеше барлык тамашачыларны җәлеп итте. Халкыбызның иң матур гореф-гадәт, йолаларын чагылдырган, милли мәдәни үзәгебез булган сабантуй мизгелләрен бик оста сәхнәләштергәннәр укучылар. Биредә зур осталык белән татарча көрәш тә, капчык киеп узышу, йомырка кабып чабулар, капчык белән бәрешүләр һәм башкалар. Шул ук вакытта һәр күренеш төрле җыр-биюләр, нәфис сүзләр, уен-көлкеләр белән бәйләнеп бара. «Сабантуй» күренешенең башыннан ахырына чаклы яшь гармунчылар түгәрәге членнарының гармуннарда уйнап, дәртләндереп, торуыннан гыйбарәт. Тамада ролен башкаручы 4 нче класс укучысы Рушан Мөхәммәтов «Сабантуй» күренешләрендә аерылып торды, үзен чын тамада итеп күрсәтеп, рәхәтләндереп көлдереп утыртты. «Сабантуй мәйданын» дер селкетеп, барлык биюләрне җиренә җиткереп башкарган Илсур Мусин белән Илнур Мөхәммәтов тә мактауга лаек. Алып баручылар Гөлүсә Мөхәммәтова һәм Фиалка Мөхәммәтова да үзләренә тапшырылган концерт программасын оста һәм кызыклы итеп алып бардылар.

Ф. МӨХӘММӘТОВА.
Югары Норлат авылы.

Кәкре Атау авылы турында сөйләгәндә аның иген кырларын, печәнлекләрен Чирмешән елгасы, күлләр әйләндереп алган, әрәмәләр матурлап тора дип әйтәсе килә. Гомер итәргә моннан да матур урын юктыр кебек. Ни генә әйтсәң дә, бу якларга матурлык өләшкәндә табигать саранлык күрсәтмәгән.

Шулай булса да яшьләрнең күңелен һаман шәһәр тарта. Анда концерт, театр, кино, чиста эш, матур итеп ял итү.

Шулай да булсын. Ә Расыйх менә барыбер туган якларын, авылын калдырып китә алмады. Ул хуш исле болыннарсыз, саф сулы елгасыз ничек яши алсын ул таш бик эчендә. Шулай уйлагандыр дип өздереп әйтә алмыйм. Әмма шунысы хак, Расыйх солдат хезмәтен тутырып кайтканнан бирле туган авылында эшли. Һөнәрен үз итеп яратып сайлап алды. 7 ел тракторчы булып эшли. Ә аның ЮМЗ-6 маркалы тракторы һәрдаим эштә. Авыл өчен бик кирәкле техника ул.

Рәсемдә: тракторчы Р. Сәгыйров.

Тәрәзәләрдә—утлар

Авыр крестьян хезмәте вакытны да, көчне дә күп сорый. Ләкин кеше берөзлексез эшләп кенә тора алмый. Аңа эш көнен башлаганчы аз гына булса да ял кирәк. Бу ял вакытын һәркем үзенчә уздыра. Мин сезгә шуның бер очрагы, төгәлрәк итеп әйтсәк, аны оештыручы кеше турында сөйләргә телим.

Кизләү авылы китапханәсенә килегез сез, бер дә үкенмәссез. Монда сезне ягымлы елмаюлы бер хатын каршылар. Гөлсирә Кәрим кызы Усманова ул. Башта аның якты йөзенә карап сагая төшәсең. Чөнки соңгы вакытта без тупаслыкка, икейөзлелеккә күбрәк ияләшә төштек. Шуңа күрә монда да шикләнәсең. Әмма күз ияләшүгә аның эчкерсезлегенә инанасың. Гөлсирә апаның холкына тынгысызлык хас. Беркемне дә игътибарсыз калдырмый, кемгә нәрсә тәкъдим итәргә икәнен дә белә. Әгәр кеше сораган әсәр китапханәдә булмаса, аны махсус дәфтәргә язып ала. Норлатка барып шуны эзләп таба. Әйтергә кирәк, безнең китапханә бик тә бай. Рус, совет, чит ил классиклары әсәрләренең тулы басмалары да һәм яңа гына исеме күренә башлаган яшь авторларның әсәрләре дә күп монда. Балалар әдәбияты да бай. Русча һәм татарча китаплар пөхтә итеп тезеп куелганнар, теләгән китабыңны бер авырлыксыз эзләп табасың.

Язын һәм көзен, аяк асты пычрак вакытта кырда да, үз бакчанда да эшнең иге-чиге юк. Кичен арып кайткач урамга чыгасы да килми. Ә Гөлсирә апа шундый чакны көтеп кенә торган диярсең. Сумкасына китаплар төйи дә өй рәтенә йөрергә чыга. Ул даими кешеләр арасында, аларның кәефләрен белә, теләк-мәшәкатьләрен аңлый һәм кулыннан килгән һәртөрле ярдәмен кызганмый. Кемгәдер рецепт буенча дарулар алып кайта, башкасына башкача булыша. Җәен чөгендер эшкәртүдән дә читтә калмый Гөлсирә апа.

Шунысы гына күңелне кырып тора: безнең китапханәдә бик салкын. Киекле авыл Советы һәм «Чишмә» колхозы җитәкчеләренә олы зарыбыз бу безнең. Кайвакыт урамда бина эченнән дәгедән җылырак та була әле. Һәрвакыт кешеләр йөреп торган клубта нормаль шартлар булдыру шулай хәл ителмәслек эш микәнни соң? Кешеләр килаләр, әмма озаклап утырмыйлар—чөнки салкын анда.

К. ИЗМАЙЛОВА.

Сез сораган идегез

Берьюлы ике эштә эшләп буламы?

Соңгы вакытта редакция почтасында, илдәге экономик үзгәрешләр тәэсире булса кирәк, хезмәт, аңа түләү шартлары, берьюлы ике урында эшләү мәсьәләләре белән кызыксынып язылган хатлар ешрак очрый башлады. Әлеге хатларга җавап бирү максатыннан газета хәбәрчесе Октябрь районының юридик консультациясе мөдире Г. Н. Голубевага берничә сорау белән мөрәҗәгать итте. Түбәндә сораулар һәм аңа җаваплар урнаштырабыз.

СОРАУ: Берьюлы ике урында эшләү кемнәргә рөхсәт ителә?

ҖАВАП: Берьюлы ике урында эшләү халык хуҗалыгының теләсә кайсы өлкәсендә эшләүче эшче һәм хезмәткәрләргә, җитәкчеләргә, белгечләргә, идарә органнары хезмәткәрләренә, профессор-укытучылар составына, фәндә, медицинада һәм башка тармакта хезмәт куючыларга рөхсәт ителә. Әмма бер шарт белән: икенче урында эшләү төп хезмәтеңнән бушаган вакытта башкарылырга тиеш.

Балигъ булмаганнарга һәм йөкле хатыннарга берьюлы ике эшкә урнашу тыела. Бу тыю аларның сәламәтлеген саклау максатын күздә тота. Әгәр берьюлы ике урында эшләү кешенең сәламәтлегенә зыян китерердәй булса яки хезмәтне башкару дәвамында куркыныч яный торган, шартлар тудырырга мөмкин икән, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләре профсоюз комитеты белән берлектә бер кешегә ике урында эшләүне рөхсәт итмәскә тиешләр. Моннан тыш, берьюлы ике җитәкче вазифаны башкару да (мастер вазифасыннан кала) тыела. Бу очракта коллектив җитәкчеләре һәм җитәкче урынбасарлары күздә тотыла. Әмма теләсә кайсы җитәкченең төп вазифасыннан тыш гади эшче (хезмәткәр) буларак эшләргә хакы бар.

Илебездә кооперацияне тагын да үстерүгә бәйле рәвештә җитештерүче кооперативларда берьюлы ике җирдә эшләү рөхсәт ителә. Бу мәсьәлә белән тирәнрәк кызыксынучыларга «СССРда кооперация турында»гы закон белән махсус танышырга рөхсәт ителә.

СОРАУ: Берьюлы ике урында эшкә урнашу тәртибе нинди?

ҖАВАП: СССР Министрлар Советының 1988 елның 22 сентябрендә кабул ителгән №1111 нче карары нигезендә берьюлы ике урында эшкә кабул итү шартлары буенча 1989 елның 9 мартында яңа кагыйдәләр гамәлгә кертелде. Алар урнашу мәшәкатьләрен элеккеге тәртипләр белән чагыштырганда шактый җиңеләйтәләр. Мәсәлән, бу карар нигезендә, икенче эшкә урнашу өчен төп эш урыныннан рөхсәт кирәкми. Әгәр икенче урындагы эштә махсус белемле булуың сорала икән, администрация синнән диплом яки белемең, профессиональ хәзерлегең турында башка төрле документ таләп итәргә хаклы. Эшкә алыну әчке тәртип кагыйдәләре нигезендә приказ белән рәсмиләштерелә.

Төп эш урыннан рөхсәт таләп ителми башлагач, төрле белешмәләрнең дә кирәге калмады. Әмма эшкә урнашучы үзенең төп эш урынын күрсәткән белешмәне яңа урында тапшырырга тиеш. Бу керем налогын исәпләү өчен кирәк. Әлеге белешмәне тапшырмаган очракта закон тарафыннан җаваплылык каралган. Берьюлы ике урында эшләүчеләрнең билгеләнгән тәртиптә эшкә кабул ителүе өчен җаваплылык эшкә алучы предприятие, учреждение, оешма администрациясенә йөкләнә.

СОРАУ: Эш вакыты, ял тәртибе һәм хезмәткә түләү турында да аңлатып китсәгез иде.

ҖАВАП: Ике урында эшләүче эшче һәм хезмәткәр көн саен дүртәр сәгать эшли ала. Ә төп эшеннән буш булганда, ял көннәрендә, отгулларда, вахта арасындагы ял чорында, отпуск ялының бер өлешендә тулы эш көне (смена) эшләргә рөхсәт ителә. Өзлексез эшли торган предприятиеләрдә, шулай ук кайбер тармакларда хезмәт шартларына яраклы рәвештә көн саен дүртәр сәгать эшләүне тәэмин итеп булмаса, эш вакытының гомуми сәгатьләр исәбе алып барылырга да мөмкин. Ләкин теләсә кайсы очракта да икенче урындагы эш сәгатьләренең гомуми күләме бер айда айлык эш вакыты нормасының яртысыннан артмаска тиеш. Бу кагыйдәдән чыгарылма буларак бары тик кече медицина персоналы гына икенче урында да айлык эш нормасы күләмен башкарырга хокуклы. Шулай ук әлеге күләмдә 1988 елның 22 сентябренә кадәр эшләп килгәннәргә вакытлыча ташлама ясала.

Кагыйдә буларак, җитештерү белән бәйләнмәгән тармакларда (педагоглар, медицина хезмәткәрләре һәм тренерларга) гына берьюлы берничә урында эшләргә мөмкин, калган барлык кешеләргә берьюлы ике урында эшләү рөхсәт ителә.

Ике урында эшләүчеләргә еллык отпуск төп эш урынындагысы белән бер үк вакытта бирелә. Әмма бу ял һәммә кешегә дә түләүле диган сүз түгел. Кагыйдә буенча ул эшчеләргә, мәктәптә, урта-махсус, һөнәр уку йортларында үз белгечлеге буенча укытучыларга, мәктәпкәчә, мәктәптән тыш һәм башка балалар учреждениеләрендә эшләүче педагогларга сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат учреждениеләрендә эшләүче медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә генә түләнә. Әгәр икенче эш урынындагы отпуск төп эштәгедән кыскарак икән, эшләүченең соравы буенча аңа түләүсез ял бирелергә мөмкин.

Хезмәткә башкарылган эш күләменнән чыгып түләнә. Премияләр, өстәмәләр һәм башка түләүләр әлеге предприятиедә каралган гомум тәртипләр буенча оештырыла.

Шунысын да белеп тору мөһим: пенсия һәм авырганда яки эштә имгәнү очракларында пособие билгеләгәндә икенче урында эшләгән өчен түләү каралмаган. Бу очракта үз белгечлеге буенча эшләүче педагогларга гына ташлама ясала.

СОРАУ: Әгәр администрация үзе хезмәт килешүен өзәргә теләсә?

ҖАВАП: Аның моңа тулы хакы бар. Килешүне өзү гамәлдә булган гадәти тәртиптә эшләнә. Мәсәлән, администрация тәкъдиме белән эштән бушату өчен профсоюз комитетының ризалыгы кирәк.

Эшләүче урынына даими кеше алган очракта яки эш шартларын вакытлыча гына килеп эшләүче канәгатьләндермәсә, бу очракта да хезмәт килешүен өзәргә сәбәп бар, һәм монда инде профкомның ризалыгы соралмый. Икенче урындагы эштән киткәндә гадәттә бирелә торган пособие түләнми. Эштән бушату турында администрация тарафыннан алдан белдереп кую өчен срок билгеләнмәгән.

Эшләүченең теләгенә карап, аның хезмәт кенәгәсенә төп эш урынындагы администрация икенче эштә дә эшләве хакында да яза ала. Әгәр ике урында даими эшләүче төп эшеннән китеп, кыска арада яңа эшкә урнаша икән, аның хезмәт стажы өзелми.

Әгәр инде эш урынында дәгъвалар килеп чыга калса, алар әзлекле рәвештә хезмәт дәгъваларын хәл итүче комиссиядә, профсоюз комитетында һәм район халык судында каралалар.



Узган ел җәй игенче өчен бик кын килде. Шуңа да үстерелгән мул уңышны җыеп алуга бөтен халык дәррәү күтәрелде. Олылар да, яшьләр дә уракта катнашырга омтылды. Колхозның механикалаштырылган ындыр табагы да кызу нокта иде. Насыйбуллин Якуб Галимханович автомат-телефон станциясендә, Гимаев Нәгыйм Галимҗанович электрик булып эшлиләр. Ринат әле бөтенләй укучы. Хәер, ул СПТУда механизаторлыкка укый, үзенең туган колхозында эшләячәк.

Әмма алар урак вакытында ындыр табагына килгән ашлыкны чистартуда, сортларга аеруда эшләделәр. Аларның тырышлыгы белән бирегәге механизмнар тәүлек буе эшләп торды, ашлыкның бозылуына, югалуына юл куелмады.

Безнең фотохәбәрчебез «40 лет Победы» колхозы эшчәннәрен җәйге чорда фотога төшергән булган.

Рәсемдә: Я. Г. Насыйбуллин, аның улы Р. Насыйбуллин һәм Н. Г. Гыймадиев.

„Сау бул, кышкай"

Күптән түгел **«Мамык»** совхозында «Кышны озату» бәйрәме булып үтте. Ак ялмалы кышны егетләр һәм кызлар бергәләп атларга утырып озатырга булдылар. Бәйрәмне һәркем күңелле ясарга омтылды. В. П. Улангина үзенең яраткан җырларын, Г. Савельева кызы белән такмаклар башкардылар. Мәктәп белән балалар бакчасы коллективлары аеруча активлык күрсәттеләр.

Җитез гәүдәлелар, көчлеләр аркан тартыштылар, тагаракларда шудылар. Тәмле чәйләр эчеп күңелле генә кышны озатып җибәрдек.

А. ОРЕНБУРОВА.

Профессияләре—терлекче

Якушкино авылы 1990 елга кадәр «Родина» колхозы составына керә иде. Үткән елның январь аенда шул авыл базасында «Заря» колхозы төзелде. Яңа хуҗалык оешу сәбәпче булдымы, колхозчылар беренче көннәрдә үк зур теләк белән эшкә алындылар. Колхозда яшьләр белән эшләүгә аеруча игътибар бирелә. Күптән түгел генә мәктәпне тәмамлаган Евгений Морозов, Юрий Боков, Алексей Яковлев, Юрий Казаков мөстәкыйль рәвештә комбайннарга утырдылар һәм уңышлы гына эшләделәр. Авылларының аерым колхоз булып оешуын ишеткәч, Владимир Убамзаров кебек читкә чыгып китүчеләр дә туган төбәкләренә кайта башлады.

Колхозда аренда ысулы белән эшләү дә инде менә ныклы тамыр җибәрде. Сөтчелек фермасында башта Акмурзиннар гаиләсе генә иде. Инде аларга Ермошкиннар да өстәлде. Биредә әле башка гаиләләр дә шул ук ысул белән эшлиләр. Шулай да Зинаида Николаевна һәм Владимир Викторович Ермошкиннар тәрбиясендә маллардан алынган нәтиҗәләр аеруча сөенерлек булды. Алар үзләренә беркетелгән 50 баш сыерның һәрберсеннән уртача 3872 килограмм сөт савып алдылар. Әлбәттә биредә аренда ысулы белән эшләүнең эффектлы булуы өстенә, аларның терлекчелектә күп еллар эшләп туплаган тәҗрибәләренең дә ярдәме зур булды. Чөнки алар икесе дә: Зинаида Николаевна 1967 елдан, ә Владимир Викторович 1969 елдан бирле даими рәвештә бер тармакта эшләп киләләр, профессияләре— терлекче аларның. Хезмәтне белеп оештыру, терлекләрне ашату-карауга даими игътибар булдыру аркасында алар январь аенда һәр сыердан уртача 308 килограмм сөт саудылар. Февраль аенда да күрсәткечләре тәүлеккә уртача 10 килограммнан төшкәне булмады. Шуңа күрә хезмәтләренең нәтиҗәсенә карата эш хаклары да әйбәт аларның. Колхозда аларга исәп-хисапны кварталлап ясыйлар икән. Квартал саен икесенә 4 мең сумнан артык акча керә бара, үз хуҗалыгын да тоткан гаиләдә бу бер дә аз акча түгел. Хәер, аларның гаиләләре дә ишле. 7 бала үстерәләр. Өлкән кызлары Люба быел Тәтеш педагогия училищесын тәмамлый, кечесе Анюта бакчага йөри, ә Алена, Наташа, Костя, Денис мәктәп укучылары. Икенче кызлары Оля кияүгә чыгып авылда калган, ул да чөгендерче булып та, савучы булып та эшләп килә. Зур гаиләнең өлкән балалары ата-аналары янына булышка фермага көн саен йөриләр. Арендачы Ермошкиннарның уңышында аларның да өлеше бар диган сүз. Хәер, Владимир Викторович үзе дә ишле гаиләдә үскән. Аның алты туганының бишесе шулай ук үзләренең туган колхозларында эшлиләр. Әниләренә ярдәм итеп, төп йортка җыелып, шау-гөр килеп бәйрәмнәрне бергә үткәрәләр, бер-берсәнең эш һәм тормыш шатлыкларын уртаклашып яши алар.

Бу тырыш терлекчеләрнең эше турында колхоз партия оешмасы секретаре Вениамин Удьянович Ишкуллин зур канәгатьләнү белән болай ди:

—Колхозыбызда терлекчелектән мул продукция алуда зур өлеш кертәләр алар. Соңгы айларда савымчыларыбыз үзләренә беркетелгән һәр сыердан тәүлеккә 10 килограммнан артык сөт савып алалар икән, бу Ермошкиннар гаиләсенең дә зур хезмәте дигән сүз.

В. ӘХМӘТҖАНОВ.

БЕЛОРУССИЯ ССР. Гомель өлкәсе Светлогорск район Советы башкарма комитеты һәм Давыдов авыл Советы вәкилләре Н. Ф. Скурчаевка дәүләт акты белән файдалануга җир бирделәр. Райондагы беренче фермерга 23 гектар җир бирелде.

Скурчаевның хуҗалыгы зур түгел: 15 сыеры, 20 бозавы бар. Шулай да кыенлыклар җитәрлек. Каян житте аннан җыештырылган тракторга техник карау кирәк. Билгеле, һәр эштә башлап йөрүчегә авырга туры килә.

Рәсемдә: «Ит беркемгә дә кирәк түгелме икән?» —дип гаҗәпләнә Н. Ф. Скурчаев.

Ярдәмегезгә мохтаҗбыз

Норлат ягында туып-үскән, шунда гомер итүче якташларыбызга, газиз милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез.

Газиз кардәшләр шушы көннәрдә Норлатта икенче мәчет төзелә башлаячак. Моңа ТССР Министрлар Советыннан рөхсәт алынды, ә Шәйхелислам мөфти Тәлгать Таҗетдин Указы буенча булачак мәчеткә 379 нчы мәхәллә номеры бирелде. Мәхәллә рәисе һәм имам итеп Заһир Кыям улы Хөснетдинов билгеләнде.

Йөрәкләрендә иман нурлары сүнмәгән Норлат кешеләренең һәрберсе безгә булышлык күрсәтә ала. Якташлар, бу зур эшне башкарып чыгуда сезнең дә ярдәмегезгә мохтаҗбыз!

Акчалата ярдәм итәргә теләсәгез, безнең счет: 701008. ТССР, Норлат шәһәре, Агропромбанк.

Табышмак-башваткыч

Бик борынгы заманда да түгел, хәзерге вакытта да булмаган бу вакыйга, ә булуын шулай да булган. Ул чорда безнең якларда бик халыкчан, бик акыллы бай кеше яшәгән ди. Аның берсеннән-берсе акыллы, бик чибәр ике малае үсеп җиткән. Бердәнбер көнне байның карчыгы дөнья куя. Ул үзе дә инде карт була һәм башында бер уй йөртә башлый: «Менә мин дә үләрмен, әгәр байлыгымны һәм үз карамагымдагы халкымны малайларымның икесенә бүлеп бирсәм, гомерләре буена ызгышып-талашып яшәячәкләр, аларга карап халык та сугышыр», дип уйлый акыллы карт.

Шулай да ул билгеле бер карарга килә. Көннәрдән бер көнне барлык халкын җыя һәм малайларын чакыра.

—Улларым,—дип эндәшә ул.—Атлар арасында икесе дә бер үк төсле ике ат барын беләсез. Әнә шул атларга атланыгыз һәм шул җиргә барыгыз, узышып кайтыгыз. Кайсыгызның аты арттан кайта, барлык байлык та шуңа.

Малайлар аталарының әмерен төп-төгәл үтиләр. Атларга атланып старт билгеләнгән урынга баралар. Тик берсе дә алдан кузгалмый. Аталары бит байлыкны арттан кайтучыга бирәм диде.

Болар шул рәвешчә бик озак басып торгач, янннарына аксакаллы бер карт килә һәм нибары өч сүз әйтә. Малайлар шуннан соң бик каты узышып китәләр. Байлык арттан кайтучыга тапшырыла.

Я кем җавап таба, аксакаллы карт нинди өч сүз әйткән?

И. ШӘЙХИЕВ.

СПОРТ

Чаңгы

Чаңгы шуу вакыты артта калды. Яз үзенекен даулый. Күптән түгел шәһәрнең 3 нче мәктәбе базасында кышкы спорт сезонын ябу булды.

12 команда арасында кискен көрәш барды. Кызлар арасында 3 километрга узышуда Түбән Чаллыдан А. Леонтьева җиңү яулады. Икенче булып финишка Каравыл Тавыннан А. Якимова килде, Богдашкино урта мәктәбеннән Т. Белова өченче урынны алды.

Шул ук дистанциягә барган хатыннар арасында НГДУдан В. Демьянова беренче, М. Галимова икенче, «Правда» колхозыннан Л. Михайлова өченче урынга чыкты.

Егетләр 5 километрга көч сынаштылар. Кискен көрәштә Д. Соловьев (2 нче мәктәп) җиңү яулады. А. Якимов (Каравыл Тавы) аңа 13 секундка калышты. Өченче урынны Түбән Чаллыдан А. Власов алды.

Ярышны 5 километр дистанциягә узышкан ир-егетләр төгәлләде. Биредә СССРның спорт мастеры Г. Погодкин («Правда» колхозы) җиңү яулады. Икенче булып В. Трофимов (НГДУ) килде, өченче урынга Э. Жирнов (НГДУ) чыкты.

Мәктәпләр арасындагы команда урыннары түбәндәгечә: беренче урында Түбән Чаллы, икенчедә—Каравыл Тавы, өченче урында 3 нче мәктәп командасы.

Физкультура коллективлары командалары арасында беренче урын НГДУда, икенче—«Правда» колхозы, өченчедә Кузнецов исемендәге колхоз командасы.

Кече футбол

14 мартта беренче мәктәп базасында кече футбол буенча блиц-турнир уздырылды.

Уеннар әйләнмәле система барды. Нәтиҗәдә 4 нче мәктәп командасы беренче урынны алды, 3 нче мәктәп икенче, 1 нче мәктәп өченче урыга чыкты.

Икенче көнне өлкәнрәк группа малайлары көч сынашты. Биредә кискен көрәштән соң өченче мәктәп командасы җиңү яулады. Икенче урынны 2 нче, өченче урынны 1 нче мәктәп командалары алды.

Ярышлар тәмамланганнан соң иң яхшы уенчылар билгеләнде һәм алар призларга, ВЛКСМ райкомының Мактау грамоталарына лаек булдылар.

Х. ФАҢУЧЕВ.

Көч сынашу дәрт бирә

Ул көнне шәһәрнең 4 нче номерлы урта мәктәбе тирә-юне укучыларның шат авазларыннан гөр килеп торды. Көне дә нәкъ менә алдан сөйләшеп куелган диярсең, үзеннән-үзе урамга, чаңгы юлларына чакырып тора торган матур, кояшлы иде. Ул көнне укучылар иртәнге 8ләргә спорт формаларында мәктәпкә җыелдылар. Ә дәресләр булмады. Чөнки бу көн алдан ук мәктәп күләмендә «Сәламәтлек көне» дип игълан ителде. Һәм инде ул көнне һәр класска үзләрен физик яктан ни дәрәҗәдә көчле икәнлекләрен күрсәтергә кулай вакыт иде. Шулай да һәр класс укучылары бөтен көчләрен куеп ярыштылар. «Сәламәтлек көне» планы укучыларның яшьләренә карап төзелеп, алдан ук мәктәпнең пресс-үзәгенә язып эленгән иде. Спорт уеннары һәм ярышларда V—XI класслар катнашты. Түбәнрәк V—VII класс укучылары төрле эстафета уеннарында көч сынаштылар. 5а—5б кызлары эстафета уеннарында да I—II урыннарны бүлештеләр. Ә малайлар арасында 5г классы беренче булды. VI класслардан малайлар арасындагы бу төр ярышларда 6в—6а, кызлардан 6б һәм 6а класслары призлы урыннарга чыктылар.

7 нче класс кызлары арасында эстафета уеннарында баштагы ике урынга 7б һәм 7а класс кызлары лаек булды. Баскетбол уеннарында 8а класс кызларына тиңнәр табылмады. Ә инде 8в класс малайлары да баскетбол ярышларында җиңүчеләр булдылар.

Ул көнне 9 нчы класслар ярышларны баскетбол уеннарыннан башладылар. Баштан кызлар уйнады, аннан соң малайлар көч сынашты. Кызлар арасында 9а, малайлардан 9б класслар җиңеп чыктылар.

«Сәламәтлек көне»ндә укытучылар да читтә калмады. Башлап ир-ат укытучылар белән 10—11 класс егетләреннән торган җыелма команда көч сынашты. Һәм укытучы абыйларына егетләр 24:18 исәбенә оттырдылар. Шул ук класс кызларыннан торган баскетбол командасы хатын-кыз укытучылар белән уйнадылар. Монысында да, укытучы хатын-кызлар кызларны җиңеп беренче булдылар.

Аннан соң 8—9 нчы класслар кызлары—2 километр, малайлары—3 километр дистанциядә чаңгыда узыштылар. Ярышны 8 класс кызлары башлады һәм 8а дан Людмила Ефремова—беренче, 8в классыннан Альмира Бильданова икенче, 8а дан Әлфирә Җәлалова өченче булып килделәр. Аннан малайлар узышты. Нәтиҗәдә 8в дан Алексей Ельин 1, 8а дан Сергей Трубкин икенче, 8в класс укучысы Олег Трофимов өченче урынга лаек булдылар.

9 нчы класс кызлары арасыннан баштагы өч призлы урынны да 9а класс кызлары Лариса Герасимова, Флюра Гайнуллина һәм Гөлназ Миннеголова бүлештеләр.

Егетләр дә үз чиратларында сынатмадылар. Бигрәк тә 9б класс укучысы Алексей Кулагинга тиңнәр булмады. Ул 3 километр араны 9 минут 36 секундта килеп беренче булды. Ә аннан соңгы икенче урынны шул ук класстан Ирек Моратов белән Николай Захаров алдылар. 9а дан Альберт Хәйруллин өченче килде.

Гомумән алганда, бу «Сәламәтлек көне»ннән укучылар канәгать калдылар һәм инде һәркем мондый күңелле мизгелләр бирүче чараларны, киләчәктә ешрак үткәрергә дигән фикер белән таралды.

Ф. ЗӘКИУЛЛИН.

Халык депутатларының Норлат шәһәр Советы башкарма комитеты КАРАРЫ

Норлат шәһәре № 18 12 март 1991 ел

Язгы чорда шәһәр урамнарында барлык маркадагы транспортлар һәм йөк автомобильләренең хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

Язгы чорда шәһәрдәге юлларның һәм башка корылмаларның саклануын тәэмин итү максатында халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты КАРАР БИРДЕ:

1. 1991 елның 25 мартыннан алып Норлат шәһәре урамнарында барлык маркадагы К-700 һәм Т-150 тракторлары һәм йөк автомобильләре хәрәкәтен аерым күрсәтмә булганга кадәр чикләргә. Искәрмә буларак, кибетләргә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләренә азык-төлек, промышленность товарлары, төзелеш объектларына материаллар ташучы йөк автомобильләренә шәһәр урамнарында йөрү маршруты күрсәтелгән пропусклар буенча гына рөхсәт ителә.

Иң кирәк чакта гына рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 3,5 тоннадан артык булган транспорт средстволарына автоюлларга китерелгән зыянны компенсацияләү шарты белән пропуск бирелергә мөмкин.

Пропускларны 25 мартка кадәр акча күчерү юлы белән, китерелгән зыянны түләүгә бурыч йөкләү турында килешү нигезендә предприятиеләр, оешмалар, колхозлар һәм совхозлар ала алалар.

2. Йөк автомобильләре һәм транспортларның хәрәкәтен түбәндәге маршрутлар буенча билгеләргә:

а) Мамык—Норлат, Андреевка—Норлат, Иске Чаллы—Норлат маршрутлары буенча килүче МТЗ-50, Т-40, Т-20 тракторларына һәм 3,5 тоннага кадәр йөк күтәрешле автомобильләргә шикәр заводына шәһәрнең төньягыннан әйләнеп, Ленинград урамы буйлап, шикәр заводы юл үткәргече аша үтәргә.

б) шул ук маршрут буйлап килүче, шул ук төр транспортта элеваторның икенче дворына, химия базасына Кормыш—аэропорт әйләнгеч юлы, тимер юл переезды аша Куйбышев урамы буйлап барырга:

в) Тимерлек—Норлат маршруты буйлап килүче шул ук төр транспортта шикәр заводына, элеваторның икенче дворына, «Сельхозхимия» базасына Кормыш—аэропорт әйләнгеч юлы, Октябрь урамы буйлап тимер юл переезды, Куйбышев урамы буйлап барырга, Нефть базасына, күмер складына, «Ремтехпредприятие» берләшмәсенә Октябрь урамы буйлап барырга.

г) Югары Норлаттан һәм Иглайдан килүче МТЗ-50, Т-40, Т-20 тәгәрмәчле тракторларына, йөк автомобильләренә сөт-май комбинатына һәм «Ремтехпредприятие» берләшмәсенә Линейная, Куйбышев урамнары буйлап нефть базасы янындагы тимер юл переезды аша бару рөхсәт ителә,

д) Түбән Норлат—Норлат маршруты буйлап килүче МТЗ-50, Т-40, Т-20 тәгәрмәчле тракторлар, йөк автомобильләре шикәр заводына Куйбышев урамы буйлап, ә сөт-май комбинатына һәм «Ремтехпредприятие» берләшмәсенә нефть базасы янындагы тимер юл переезды аша үтәләр.

3. Район эчке эшләр бүлеге начальнигы В. В. Ивановтан бу карарны үтәүдә булышлык күрсәтүен сорарга.

М. ФӘРРӘХОВ,
Норлат шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе.

БЕЛДЕРҮ

Бөгелмә наркология диспансеры дәвалау үткәрә:

1. Хроник алкоголизмнан. Кулланыла: гипноз, энә терапиясе, кодка салу, «Торпедо» методы, «Эспераль» имплантация, төелгысыз эчүдән купирлаштыру юлы куллану.

2. Тәмәке тартудан.

3. Нерв авыруларыннан.

4. Алкоголизм, наркомания, токсикомания белән авыручыларның гаиләләренә дәвалауда һәм консультациядә ярдәм күрсәтә.

Адрес: ТССР, Бөгелмә шәһәре, Стрелочная урамы, 18а йорты. Наркодиспансер. Телефон: 5—12—27. (1, 11, 7 номерлы автобуслар белән «65 мәктәп» һәм «Вокзал борылышы» тукталышларына кадәр килергә).

Мөхәррир урынбасары **Р. З. АИЗАТУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—61, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары —2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—61, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны ФИДАНИЯ ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Асия МОРАТХАНОВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 34. Тираж 3.350.